РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

2023 елның 20 сентябре №22

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү, җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган күчмә милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту эшен оештыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 60, 62, 76 статьяларына, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 222 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү, җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган күчмә милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЯДЫГЕРЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1021607752836 Совет Ядыгерьского сельского поселения ИНН 1623001639

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 сентябрендәге 22 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү, җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган күчмә милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе турында нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы таләпләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Нигезләмә мәгълүматның ачыклыгы һәм файдалану мөмкинлеге, шулай ук үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчмә милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) турындагы карарларның законлылыгы принципларына нигезләнә һәм, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына карамастан, барлык гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

1.3. Әлеге Нигезләмә муниципаль милектәге җир кишәрлегендә яки дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә һәм муниципаль милектә булган башка күчемсез милектә урнашкан үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү һәм законсыз урнаштырылган күчмә милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибен регламентлый.

1.4. Законсыз урнаштырылган күчемсез милек – Ядегәр авыл җирлеге территориясендә (күчемсез милектә) Ядегәр авыл җирлеге законнарында, норматив хокукый актларында каралган хокукый нигезләрсез һәм/яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып урнаштырылган күчмә объект (шул исәптән вакытлыча), шул исәптән, әгәр күчемсез милек булмаган вакытлыча объект(-лар)ны урнаштыру тиешле шартнамәдә каралмаган булса, шулай ук урнаштыру хокукы туктатылган булса.

1.5. Күчмә милек булып түбәндәге типтагы күчмә объектлар тора: стационар булмаган сәүдә объектлары( вакытлыча корылмалар, вакытлыча конструкцияләр һәм күчереп йөртә торган корылмалар), контейнерлар, күчереп йөртә торган төзелмәләр һәм корылмалар, конструкцияләр, механизмнар, төзелеш материаллары, коймалар, ачык типтагы автостоянкалар һәм башка күчмә милек:

1) павильон – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товар запасын саклау өчен бинасы булган, бер яки берничә эш урынына исәпләнгән, аерым тора торган күп функцияле

билгеләнештәге стационар булмаган объект (шул исәптән кафе, шина монтажлау остаханәләре, автомобиль югычлар, тукталыш комплекслары, стационар бәдрәфләр);

2) киоск – сәүдә җиһазлары белән җиһазландырылган, капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товарларны саклау өчен биналары булмаган, бер эш урынына исәпләнгән, аерым тора торган стационар булмаган объект;

3) телекоммуникация контейнеры – технологик җиһазлар – автоном телефон станцияләре, телефон концентраторлары, телематик узеллар, мәгълүмат тапшыру узеллары, мәгълүмат пакетларын тарату узеллары, мәгълүмат тапшыру челтәрләре буенча сөйләм мәгълүматларын тапшыру узеллары урнаштыру өчен билгеләнгән металл конструкцияләрдән төзелгән контейнер тибындагы вакытлыча корылма;

4) металл гараж – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, автотранспорт чарасын каплау өчен билгеләнгән стационар булмаган объект;

5) контейнер – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, товарлар урнаштыру өчен билгеләнгән тулысынча яки өлешчә ябык савыттан гыйбарәт транспорт җиһазы (клетка, алына торган цистерна яки шуңа охшаш җайланма);

6) койма – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, койма буларак кулланыла торган металл, агач яки башка материалдан эшләнгән конструкция;

7) теплица – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, яктылык үтә торган материалдан капланган, теплица культуралары һәм үсентеләр үстерү өчен кулланыла торган стационар булмаган объект;

8) кладовой – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, азык-төлек, утын, инвентарь һ.б. саклау өчен кулланыла торган стационар булмаган объект;

9) сарай – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, хуҗалык кирәк-яраклары саклау, йорт малы асрау һ.б. өчен кулланыла торган стационар булмаган объект;

10) будка –капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, эшчеләрне һәм сакчыларны урнаштыру өчен бина буларак кулланыла торган стационар булмаган объект.

1.6. Законсыз урнаштырылган күчемсез милек – Ядегәр авыл җирлеге территориясендә (күчемсез милектә) Ядегәр авыл җирлеге законнарында, норматив хокукый актларында каралган хокукый нигезләрсез һәм/яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып урнаштырылган күчмә объект (үз белдеге белән төзелгән корылма).

Үз белдеге белән төзелгән корылма - билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән җир яки рөхсәт ителгән файдалану анда әлеге объектны төзүгә юл куймаган җир кишәрлегендә торгызылган яки төзелгән, яисә закон нигезендә кирәкле килешүләр, рөхсәтләр алмыйча яки шәһәр төзелеше һәм төзелеш нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып торгызылган яки төзелгән бина, корылма яисә төзелмә, әгәр җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану, тиешле килешүләр, рөхсәтләр алу турындагы таләп һәм (яки) күрсәтелгән шәһәр төзелеше һәм төзелеш нормалары һәм

кагыйдәләре үз белдеге белән төзелгән корылманы торгызу яки төзү датасына билгеләнгән һәм үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау датасына гамәлдә булса.

1.7. Үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү, законсыз урнаштырылган күчмә милекне, стационар булмаган объектны демонтажлау (күчерү) мәсьәләләрен карауны Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылмаларны, стационар булмаган объектларны ачыклау буенча эшне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты каршында төзелә торган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылмаларны ачыклау һәм демонтажлау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) гамәлгә ашыра.

Комиссия эшчәнлеге әлеге Нигезләмә һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылмаларны ачыклау һәм демонтажлау буенча комиссия турында Нигезләмә белән регламентлана.

1.8. Үз белдеге белән төзелгән корылманы һәм (яисә) законсыз урнаштырылган күчемсез милекне, стационар булмаган объектны ачыклауның һәр очрагы акт белән рәсмиләштерелә, анда актны төзүнең датасы, вакыты; объектны ачыклаган орган атамасы, затның (затларның) исеме, фамилиясе, атасының исеме һәм вазыйфасы; ачыкланган объектның урнашкан урыны; ачыкланган хокук бозулар турында, бу хокук бозулар өчен җаваплылык йөкләнгән затлар турында (әгәр андыйлар билгеләнгән булса) мәгълүмат, таләпләре бозылган норматив хокукый актның статьялары һәм пунктлары; үз белдеге белән урнаштырылган объектны ачыклаганда катнашкан затларның акт белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында мәгълүматлар, аларның имзалары яки имзадан баш тартуы һәм башка мәгълүматлар күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемле милекне, стационар булмаган объектларны ачыклау турында акт төзегәндә, Комиссия ачыкланган стационар булмаган объектны урнаштырган затны (гражданны яки юридик затны) ачыклау өчен чаралар күрә, һәм әлеге затның Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турындагы акт белән танышуын тәэмин итә. Ачыкланган үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган зат акт белән танышудан баш тарткан очракта, анда тиешле язма ясала.

Ачыкланган үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат дип, әлеге Нигезләмә кысаларында, ачыкланган үз белдеге белән төзелгән объектны, стационар булмаган объектны урнаштырган һәм (яки) кулланган граждан яки юридик зат таныла.

Ачыкланган үз белдеге белән төзелгән корылманы, стационар булмаган объектны үз белдеге белән урнаштыручы зат булмаган очракта, шулай ук ачыкланган үз белдеге белән төзелгән корылманы, стационар булмаган объектны үз белдеге белән урнаштыручы затны билгеләү мөмкин булмаганда, аны демонтажлау, ташу һәм

саклау әлеге Нигезләмәнең 1.15 пунктында каралган тәртиптә башкарыла, бу хакта актта тиешле билге ясала.

1.9. Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында акт төзелгәннән соң, законсыз үз белдеге белән төзелешне гамәлгә ашырган кешегә карата Комиссия әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча ачыкланган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау турында таләп төзи.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау турындагы таләп үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) шәхсән кул куйдырып тапшырыла, яки үз белдеге белән төзегән корылманы законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган затны ачыклаганда Комиссия тарафыннан билгеләнгән адреска тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша җибәрелә.

Үз белдеге белән төзелешне законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелешне демонтажлау турындагы таләпне тапшыру белән бер үк вакытта, таләп законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылмада әйләнә-тирә мохиткә чыдам махсус чаралар белән язу юлы белән урнаштырыла.

Җир кишәрлеген азат итү турындагы таләптә күрсәтелгән үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган кеше (граждан яки юридик зат), таләпне тапшырганнан алып корылманың характерын исәпкә алып билгеләнгән вакытка законсыз урнаштырган үз белдеге белән төзелгән корылманы үз көче белән һәм үз хисабына сүтәргә тиеш. Үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү өчен вакыт өч айдан да ким һәм унике айдан да артык була алмый.

1.10. Үз белдеге белән төзегән корылманы законсыз рәвештә урнаштырган граждан яки юридик зат законсыз рәвештә урнаштырган үз белдеге белән төзегән корылманы демонтажлау таләпләрен үтәмәгән очракта, Комиссия үз белдеге белән урнаштырган үз белдеге белән төзегән корылманы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты көче белән сүтү турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) эвакуация һәм милекне саклау буенча хезмәтләр күрсәтү өчен оешмаларны «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә хокуклы.

1.11. Демонтаж датасы турында үз белдеге белән төзелешне законсыз урнаштырган затка әлеге Нигезләмәнең 1.9. пунктында каралган тәртиптә әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча хәбәрнамә (юллама) тапшыру юлы белән Комиссия тарафыннан хәбәр ителә.

1.12. Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау, ташу һәм саклау буенча эшләрне башкаруга Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты белән муниципаль контракт төзелгән зат тарафыннан башкарыла.

Демонтажлау һәм транспортлау ысулын сайлау җаваплылыгы Оешмага йөкләнә. Әгәр Оешма һәм (яки) Комиссия вәкиле фикеренчә, законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау аны таратмыйча мөмкин булмаса, бу хакта Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау актында билге куела.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау процедурасын теркәү өчен фото- яки видеога төшерүнең техник чаралары кулланыла.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылма һәм андагы милек демонтажлаганчы Комиссия тарафыннан исемлеккә кертелергә тиеш. Милек исемлегенә Комиссиянең барлык әгъзалары кул куя һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау турындагы актка кушымта булып тора.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау актын законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау тәмамлангач, әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта буенча төзелә.

Актка үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат (граждан яки юридик затның вәкаләтле вәкиле) кул куя. Әгәр ул үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлаганда ул булмаса яки имзадан баш тарткан очракта, актта тиешле язма ясала.

1.13. Демонтажланган законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылма һәм демонтаж вакытында анда булган милек милек исемлеге нигезендә демонтажланган стационар булмаган объектларны өеп кую урынына чыгарылырга тиеш, анда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты белән муниципаль контракт нигезендә әлеге милекне саклау тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Оешма, сату вакыты тәмамлану яки саклау шартлары бозылу сәбәпле, ташу һәм саклау срогы дәвамында яраксыз хәлгә килгән яисә демонтажлаганчы яраксыз хәлгә килгән товарлар өчен җаваплы түгел.

1.14. Демонтажланган законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылма һәм демонтаж вакытында анда булган милек милек исемлеге нигезендә стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затка әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

Ирекле тәртиптә түләүдән баш тарткан очракта, үз белдеге белән (законсыз) объектны ачыклау, демонтажлау (күчерү) һәм саклау чараларын башкарганда тотылган чыгымнар стационар булмаган объектны үзлегеннән урнаштырган зат тарафыннан суд тәртибендә тулы күләмдә капланырга тиеш.

1.15. Үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затны ачыклау мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы үз теләге белән демонтажлау һәм хәбәр басылып чыкканнан соң ике атна эчендә җир кишәрлеген азат итү турында

тәкъдим белән мәгълүмати хәбәрне Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны һәм «Хезмәт даны» район газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итә.

Мәгълүмати хәбәр урнаштыру белән бер үк вакытта законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылмага Комиссия тарафыннан әйләнә-тирә мохиткә чыдам махсус чаралар белән законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы, язу язылганнан соң, ирекле рәвештә демонтажлау һәм ике атна эчендә җир кишәрлеген азат итү турында таләпләр белән язу языла, шулай ук хокук саклау органнарына үз белдеге белән төзелешне законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган затны билгеләүдә ярдәм күрсәтү максатыннан сорату җибәрелә.

Әгәр законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы үз теләге белән демонтажлау һәм җир кишәрлеген азат итү тәкъдиме белән мәгълүмати хәбәр басылып чыкканнан соң 14 көн узгач, үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат ачыкланмаса, Комиссия законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау турында карар кабул итә.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау әлеге Тәртипнең 1.12 пунктында каралган тәртиптә үткәрелә.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау, аны саклау урыны һәм вакыты турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан «Хезмәт даны» район газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Демонтажланган законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылма һәм демонтаж вакытында анда булган милек милек исемлеге нигезендә стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затның гаризасы буенча, аның чыгымнары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенә әлеге Тәртипнең 1.14. пунктында каралган тәртиптә каплаганнан соң кире кайтарылырга тиеш.

1.16. Хуҗасы тарафыннан алынмаган, демонтажланган үз белдеге белән урнаштырылган стационар булмаган объект һәм демонтажлаганда анда булган мөлкәт, мөлкәт исемлеге буенча, Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты белән төзелгән килешү буенча өч ай дәвамында сакланырга тиеш.

Әгәр сүтелгән, законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектның хуҗасы өч айдан соң ачыкланмаса, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты стационар булмаган объектка ия була һәм судка стационар булмаган объектны хуҗасыз дип тану һәм, аны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә утильләштерү өчен, муниципаль милеккә тапшыру турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Стационар булмаган объектның бәясе минималь хезмәт хакының биш тапкыр күләменә туры килгән суммадан түбән булган очракта, суд карары таләп ителми .

## 2. ЗАКОНСЫЗ УРНАШТЫРЫЛГАН КҮЧМӘ ОБЪЕКТЛАРНЫ ҺӘМ МАТДИ КЫЙММӘТЛӘРНЕ САКЛАУ, ТАШУ ҺӘМ ҮТИЛЬЛӘШТЕРҮ

2.1. Вакытлыча саклау урыннарына саклауга тапшырылган үз белдеге белән (законсыз) объектлар һәм башка милек, объектларга һәм милеккә хокукны раслый торган документлар күрсәтелгәннән соң, хуҗасына тапшырыла.

Хуҗа мөрәҗәгать иткән көнне, әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тикшергәннән соң, саклау өчен җаваплы зат хуҗага вакытлыча саклау урыныннан демонтажланган үз белдеге белән (законсыз) объектларны һәм башка милекне бирү мөмкинлеген килештерү турында билге белән тапшыру-кабул итү акты бирә.

кабул итү-тапшыру акты саклау өчен җаваплы зат, үз белдеге белән (законсыз) төзелгән объектны һәм башка мөлкәтне тапшырганда үз белдеге белән (законсыз) урнаштырган объектның хуҗасы һәм Ядегәр авыл җирлеге Башкарма комитетының вазыйфаи заты тарафыннан имзалана. Актның бер нөсхәсе – үз белдеге белән (законсыз) объект хуҗасында, икенчесе – саклау өчен җаваплы кешедә, өченчесе – Ядегәр авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.

2.2. Демонтажлаганнан соң сакланган объектны һәм башка милекне алу өчен, объект хуҗасы саклаучы кешегә язма гариза белән мөрәҗәгать итә, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

2.2.1. Үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, законсыз урнаштырылган объектны һәм объектта табылган мөлкәтне демонтажлау, күчерү һәм саклау, шулай ук күрсәтелгән мөлкәтне калдыклар сыйфатында ташу һәм утильләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны түләүне раслый торган түләү документының күчермәсе.

2.2.2. Объектларга һәм милеккә хокукны раслый торган документларның (сатып алу-сату, бүләк итү, аренда шартнамәләре һәм башкалар) күчермәләре, объектка һәм анда булган мөлкәткә милек хокукын раслый торган башка документлар.

2.3. Үз белдеге белән (законсыз) объект хуҗасы тарафыннан акчалар (әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар суммасы) Ядегәр авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

Әгәр үз белдеге белән төзелгән корылмаларны сүтү, законсыз урнаштырылган объектларны демонтажлау, күчерү, саклау, ташу һәм утильләштерү, шулай ук үз белдеге белән төзелгән корылмаларда һәм законсыз урнаштырылган күчмә объектларда табылган мөлкәтне саклау, ташу һәм утильләштерү хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә нигезендә юридик яки физик зат тарафыннан түләүсез башкарылса, үз белдеге белән (законсыз) объектның законлы хуҗасы чыгымнарны әлеге чараларны гамәлгә ашырган кешегә түли.

Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны каплау күләме факттагы саклау вакытына бәйле рәвештә чыгымнарның фактик суммасыннан чыгып исәпләнә.

2.4. Әгәр хуҗа, вакытлыча саклау урынында саклана торган мөлкәтне сорап, бер ел дәвамында мөрәҗәгать итмәсә, мөлкәт Россия Федерациясе Гражданлык кодексында каралган тәртиптә муниципаль милеккә әйләндерелергә һәм аннары үз белдеге белән төзелгән объектларны сүтү, мөлкәтне күчерү һәм аны саклау белән бәйле чыгымнарны каплау максатыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә сатылырга мөмкин.

## 3. ҮЗ БЕЛДЕГЕ БЕЛӘН ТӨЗЕЛГӘН КОРЫЛМАЛАРНЫ СҮТҮ, ЗАКОНСЫЗ УРНАШТЫРЫЛГАН КҮЧМӘ ОБЪЕКТЛАРНЫ ҺӘМ АЛАРДА ТАБЫЛГАН

## МИЛЕКНЕ КҮЧЕРҮ (ДЕМОНТАЖЛАУ), САКЛАУ, ТАШУ ЯКИ УТИЛЬЛӘШТЕРҮ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЧЫГЫМНАР

3.1. Үз белдеге белән (законсыз) объектларны демонтажлау, күчерү, саклау, аларны ташу һәм күмү яки калдыклар һәм сүтелгән объектларда табылган мөлкәт буларак утильләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү әлеге чараларны гамәлгә ашыручы затлар хисабына башкарыла, аннан соң чыгымнарны үз белдеге белән (законсыз) төзелгән объект хуҗасы каплый.

3.2. Үз белдеге белән (законсыз) төзелгән объектларны демонтажлау, күчерү, саклау, аларны ташу һәм күмү яки демонтажланган объектларда табылган калдыклар һәм милек буларак утильләштерү «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль контракт төзелгән юридик яки физик зат тарафыннан түләүле нигездә башкарылган булса, чыгымнар күләмен исәпләү Ядегәр авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы А.Н.Фәйзуллин

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 1 нче кушымта

## ____ номерлы АКТ

«__» ________ 20___ ел                                        ________________

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында**

Түбәндәге составтагы комиссия

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(Комиссия әгъзаларының Ф. И. А., вазыйфасы)

әлеге актны

______________________________________________________________________________

(стационар булмаган объектның адресы һәм урнашу урыны)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(законсыз рәвештә стационар булмаган объектны урнаштырган затның мәгълүматлары: граждан өчен – Ф. И. А. һәм адресы; юридик зат өчен – атамасы, адресы, вәкаләтле затның Ф. И. А. һәм вазыйфасы)

урнаштырылган

_________________________________________________________________________,

(үз белдеге белән төзелгән корылма атамасы)

төзелгән материалы

____________________________________________________________ турында төзеде.

Әлеге җир кишәрлеге Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән тәртиптә стационар булмаган объектны урнаштыру өчен бирелмәгән.

Акт белән таныштым _______________________________________________

(үз белдеге белән төзелгән корылманы үз белдеге белән урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф. И. А., вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе ___________________________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары: ______________________________________________

(имза)

Кукмара муниципаль
районы Ядегәр авыл
җирлеге территориясендә
законсыз рәвештә
урнаштырылган үз белдеге
белән төзелгән корылманы
ачыклау һәм демонтажлау
Тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау турында таләп

«__» ________ 20___ ел ________________

Бирелде ______________________________________________________________________
_______________________________________________

(законсыз рәвештә стационар булмаган объектны урнаштырган затның мәгълүматлары: граждан өчен – Ф. И. А.; юридик зат өчен – атамасы, адресы)

үз белдеге белән урнаштырылган стационар булмаган объектка карата
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(законсыз урнаштырылган объектның исеме)

урнашкан адресы: ________________________________________________
Түбәндәге составтагы комиссия:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(Комиссия әгъзаларының Ф. И. А., вазыйфасы)

Кукмара муниципаль районы __________ авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны ачыклау турында акт төзелде
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(актның датасы һәм номеры)

20____ елның «____» __________ кадәрге вакыт эчендә үз көчегез һәм чараларыгыз белән Сезнең тарафтан законсыз урнаштырылган үз белдегегез белән төзелгән корылманы (корылманың исеме) сүтәргә тәкъдим итәбез.

Комиссия карары буенча объект 10 календарь көн эчендә сүтеләчәк һәм мәҗбүри рәвештә чыгарылачак. Законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау, ташу һәм саклау буенча барлык чыгымнар Сездән РФ законнарында каралган тәртиптә түләтеләчәк.

Әлеге таләпнең үтәлеше турында Кукмара муниципаль районы ___________ авыл җирлеге башкарма комитетына 20____ елның «____» _____________ кадәр хәбәр итүне сорыйбыз.

Таләп алынды ________________________________________________

(стационар булмаган объектны үз белдеге белән урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф. И. А., вазыйфасы, имзасы )

Комиссия рәисе: ____________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары

______________________________________________________________

(имза)

Кукмара муниципаль
районы Ядегәр авыл
җирлеге территориясендә
законсыз рәвештә
урнаштырылган үз белдеге
белән төзелгән корылманы
ачыклау һәм демонтажлау
Тәртибенә 3 нче кушымта

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау датасы турында
____ номерлы ХӘБӘРНАМӘ

Түбәндәге составтагы комиссия
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________
(Комиссия әгъзаларының Ф. И. А., вазыйфасы)

хәбәр итә
_______________________________________________
(законсыз рәвештә стационар булмаган объектны урнаштырган затның мәгълүматлары: граждан өчен – Ф. И. А. һәм адресы; юридик зат өчен – атамасы, адресы, вәкаләтле затның Ф. И. А. һәм вазыйфасы)

законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны демонтажлау
_______________________________________________
(объектның адресы һәм атамасы)

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты көче белән башкарыла
_______________________________________________
(датасы һәм Мәскәү вакыты)

Хәбәрнамә алынды
_______________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф. И. А., вазыйфасы, имзасы )

...
Комиссия рәисе: _______________________________
(имза)

Комиссия әгъзалары _______________________________
(имза)

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлауның ____ номерлы АКТы

«__» ________ 20___ ел                                        ________________

Түбәндәге составта Комиссия
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(Комиссия әгъзаларының Ф. И. А., вазыйфасы)

һәм
______________________________________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф. И. А., вазыйфасы, имзасы )

катнашында законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы мәҗбүри демонтажлау үткәрелде
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________(корылманың атамасы)

төзелгән материалы
______________________________________________________________________________

урнашкан адресы:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы демонтажлау башкарылды
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(объектны демонтажлаган юридик затның Ф.И.А. яки исеме)

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында _____ елның ___ ______________ _____ номерлы акт, җир кишәрлеген азат итү турында _____ елның ___ ______________ _____ номерлы таләп һәм Комиссиянең законсыз рәвештә урнаштырылган үз белдеге белән төзелгән

корылманы демонтажлау турында _____ елның ___ _____________ ____ номерлы карары нигезендә
Демонтаж вакытында объектның тышкы торышы:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
Объектны ачу башкарылмады (башкарылды).
Объектны таркату башкарылмады (башкарылды).
Мәҗбүри рәвештә сүтелгән стационар булмаган объект урнаштырылды
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(адресы)
һәм җаваплы саклауга тапшырылды
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________(
атамасы, Ф.И.А., вазыйфасы)

Актка кушымта: стационар булмаган объектның һәм аны демонтажлаган вакытта законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектта булган мөлкәтнең исемлеге.

Әлеге акт 3 нөсхәдә төзелде һәм тапшырылды (җибәрелде):
- Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитетына;
- үз белдеге белән төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затка (гражданга яки юридик затка)
______________________________________________________________________
(объектны саклауга алган затның исеме)
Акт белән таныштым
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф. И. А., вазыйфасы, имзасы )
Комиссия рәисе: ______________________________
(имза)
Комиссия әгъзалары
____________________________________________________
(имза)
Объектны саклауга алган зат:
_______________________________________________________
(имза)